РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОУСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА ҮСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Юрид.адрес: 423980, РТ, Муслюмовский район, с. Новые Усы, ул. Советская, 30
Факт.адрес: 423980, РТ, Муслюмовский район, с. Новые Усы, ул. Советская, 30
Тел./факс: 8-85556-32030/25866 (бух.) - Элект. адрес: Nusin.Mus@tatar.ru
ИНН 1629004001, КПП 162901001, ОГРН 1061687005302, ОКТМО 92642455

**Яңа Усы авылы** **«27» январь 2023 ел**

## КАРАР №2

### Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә 2023 елга җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары һәм «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары нигезендә Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 7793,48 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварендәге 5 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Яңа Усы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе:** **Г.С.Романова**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
Яңа Усы авыл җирлеге
башкарма комитетының 2023 елның
27 гыйнварендәге 2 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының 01.02.2023 елдан Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3974,68 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1558,69 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2260,11 |
| **Барлыгы** | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының
Яңа Усы авыл җирлеге
башкарма комитетының 2023 елның
27 гыйнварендәге 2 нче номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының 01.02.2023 елгы Мөслим авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Кәфенләү | 1247 |
| 3.Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2805,65 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1558,66 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2182,17 |
| **Барлыгы** | 7793,48 |